ХУТБА ПРАЗДНИКА РАЗГОВЕНИЯ НА ТАТАРСКОМ ЯЗЫКЕ

خطبة عيد الأضحى باللغة التترية

# КОРБАН БӘЙРӘМЕ

Аллаһ Тәгаләгә мактау-шөкерләр булсын! Мухәммәд Пәйгамбәебезгә – Салауат!

Йә, Рабби, Мухәммәд Пәйгамбәребезнең дәрәжәсен күтәр!

Ислам – Хак Дин, Аллаһы Тәгалә колларына Ислам Динен тотарга әмер итте.

Ислам – бөтен Пәйгамбәрләрнең Дине, Адәм Пәйгамбәрдән башлап Пәйгамбәребез Мухәммәд Мустафага кадәр, Аларга Сәлам булсын.

Ислам – бөтен Фәрештәләрнең Дине.

Ислам Динебез олыгъ ахлякка, намуслыкка, йомартлыкка, хәерле гамәлләр кылуга өнди.

Һәм дә хәерле вә сәваплы гамәлләрнең бере – Корбан.

Хәнәфи мәзһәбенең галимнәре әйттеләр ки: кемнең мөмкинчелеге булса, ул кешегә Корбан – важиб булыр.

Әмма Шафигый мәзһәбенең галимнәре әйттеләр: Корбан – Сөннәт Мүәккәдәһ.

Вә Корбанның мөһимлеге турында галимнәр сөйләделәр, аларның арасында: беренче Халиф Әбу Бәкр Әс-Сыддык, икенче Халиф Гумар ибн Әль-Хаттаб, Пәйгамбәребезнең мүәззине – Билял Хәбәший.

Әнәс, Радияллаһу Анһу, хәбәр итүе буенча: Пәйгамбәребезнең Корбаны – ике сарык тәкәсе иде.

Адәм Аляһиссәләм беренчедән Гыйбәдәт кылыр өчен Кәгбәне төзеде.

Бөек Туфан Кәгбәне җимергәннән соң, Аны элеке асылында Ибраһим Пәйгамбәр Аляһиссәләм яңыдан төзеде.

Әбу Зәрр бер дәм Пәйгамбәребездән сорады: «Йә, Расүләллаһ, иң беренче мәчет кайсы?» Пәйгамбәребез Мухәммәд Аляһиссәләм аңа шулай җавап бирде: «Әл-Хәрам». Әбу Зәрр тагын сорады: «Ә аннан соң кайсы?» Пәйгамәребез Аляһиссәләм әйтте: «Әл-Әкъса». Һәм Пәйгамбәребезнең әйткәне буенча, шул ике Мәчет арасында 40 йыл.

Кәгбә – безнең Кыблабыз, җирнең уртасында тора. Аның өстендә җиденче күктә Әл-Бәйт Әл-Мәгмур дигән бина бар, Анда Аллаһы Тәгаләгә Фәрештәләр гыйбәдәть кылалар. Анда бердән 70 мең Фәрештә керә, гыйбәдәт кыла, чыга һәм башкача кире кайтмый.

Әл-Хәҗәр Әл-Әсүәд – Кара таш – Ҫәннәттән иңгән ак төсле якут ташыдыр. Әмма мушрикләр тотынганнан соң Ул карайды.

Корбан бәйрәм – бөтен дөнья мөселманнары өчен иң зур бәйрәм, Бәйрәм иткәндә Гает Намазы кылына (Корбан Бәйрәм Намазы) һәм мөмкинчелеге булган кешеләр Корбан суялар. Һәм Хаҗ гамәлен үтиләр, шушы вакытта мөселманнар арасында мөхәббәт арта, берләшүгә сәбәп була.

## КОРБАН КАБУЛ БУЛСЫН ӨЧЕН НИНДИ ШАРТЛАР БАР

Корбан хайваннары – сарык, я дә сарык тәкәсе, аның бер яше тулган булсын, аннан олырак булса яхшырак, әмма аннан яшь булмасын, ә кәҗә яки кәҗә тәкәсе булса – ике яше тулган булырга тиеш. Шулай ук үгез я дә сыер булса ике яштән олы, ә дөя – биш яшеннән олы булуы кирәк.

Имам Джабир Мухәммәд Пәйгамбәребездән ошбу Хәдисне риваять итте бу Хәдисне: Пәйгамбәребез Аләйһиссәләм әйтте: «Корбан итеп иң олы хайванны чалыгыз, булмаса бер яшлек сарык тәкәсен чалыгыз».

Корбан малы сукыр булса, я дә тыштан күренә торган чире булса, аксак булса вә шуның кебек төрле кимчелекләре булса, Корбан дөрес булмас.

Корбан чалу вакыты: Корбан бәйрәме Намазының вакыты кергәннән соң ике Рәкәгать Намаз кылу вә Гает Хотбәсен укыр өчен җитәрлек вакыт үткәч башлана.

Бу вакыттан иртәрәк суелган мал Корбан булмас.

Имам Муслим һәм Әл-Бухарий Әл-Бур исемле Сахабидән риваять иттеләр ки: Корбан

Бәйрәме көне Пәйгамбәребез Алеһиссәләм Гает Намазындан соң Хотбәсендә шулай диде: «Кем безнең Намазыбызны кылып Корбан суйган булса – безнең Сөннәтебезне үеәгән булыр, ә кем малын Гает Намаздан элегерәк суйган булса, – малы Корбан булмас, яңыдан суйсын!»

Чөнки вакытында суелмаган мал Корбан итеп кабул булмас.

Корбан сую вакыты дүрт көн дәвам итә, иң соң вакыты – Корбан Гаетенең дүртенче көнендә кояш батканча.

Ислам Галимнәре шулай әйттеләр: Нинди хәл булса да Корбан итеннән бер нинди өлешен сатырга ярамый. Мал суючыларга һәм ярдәмчеләргә эшләгән өчен малның тиресен дә, итен дә бирергә ярамый, әмма эш өчен түгел, Садака кебек бирү мөмкин.

Корбан чалыр өчен иң яхшы урын – Корбан суюче кешенең җирендә я дә йортында һәм Корбанны туганнар алдында сую яхшырак.

Хаждагы Хаҗиләргә Кәффәрәтләрен Хаҗ кылынган җирдә кылу дөрес булыр.

## КОРБАННЫҢ ФӘЗЫЙЛӘТЕ

Корбанның фәзыйләте турында Пәйгамбәребез Мухәммәд, Аляһиссәләм әйтте: «Корбанны ихлас белән суегыз, һәм һәрберегез Кыйбла тарафына юнәлегез, шулай эшләсәгез, Корбанның каны өчен вә җан чыгуы өчен Кыямәт Көнендә чалучыга сәвап булыр». Бу Хәдисне Пәйгамбәребез Мухәммәд, Аляһиссәләмнең хатыны ‘Айша Радыяллаһу Анһу риваять итте.

Шуның өчен Корбан хайванын Кыйбла тарафына юнәлтеп шушы сүзләрне әйтү бик яхшы булыр:

**«بسم الله، الله أكبر»** һәм: **«اللهم تقبل مني»**

«Аллаһ Тәгалә исеме белән башлыйм, йә, Аллаһ, миннән кабул ит».

Корбан чалучы өндәмәстән, үзе белеп, чын күңеле белән чалса бигерәк тә яхшы.

Һәм иң яхшысы Корбан итен өчтән бер өлешен (⅓) Садака кебек ярлыларга бирү, ⅓ үзенә калдыру һәм калган ⅓ теләгән кешегә бүләк итеп бирүдер.

Ярлыларга гына бөтен итне өләшсә дә кабул була.

Кайсыбер кешеләр әйтәләр ки шундый бер Хәдис бар икән янәсе, мөселман Корбан чалырлык көче җитсә ә ул Корбан чалмаса, аңа әйтәләр имеш: «Мәчеткә кермә», әмма бу сүзләргә Хәдис дигән исбат юк.

## КОРБАННЫҢ ХИКМӘТЕ

Без – мөселманнар шулай ышанабыз: безнең Пәгамбәребез Мухәммәд Мустафадан соң башка Пәйгамбәр җибәрелмәс, шуңа күрә кем дә кем Мухәммәд Пәгамбәребез вафатыннан соң үзен үзе Пәйгамбәр диеп иглан итсә, төшләре турнда һәм вахи килә дисәләр дә – барысы да ялганчылардыр. Пәйгамбәр булмаган кешеләрнең төшләре вәхи түгел. Фәкать Пәйгамбәрләрнең төшләре – вәхидыр.

Ислам Галиме Катада әйтте: Пәйгамбәрнең төше – хакдыр, нәрсә күрә – шуны эшли.

Ибраһим Пәйгамбәребез турында әйтелде, Ул төшендә Исмагыйл улын Корбан итеп суйганын күргән, һәм дә бу эш – вахий, ягъни Аллаһ Тәгаләнең Әмере.

Аллаһ Тәгалә Көръәндә әйтте:

**«قال يبني إني أرى في المنام أني أذبحك»** (Әс-Саффәт Сүрәсе, 102 Аят),

Мәгънәсе: Ибраһим Пәйгамбәр Исмәгыйл улына әйтте: «Мин сине Корбан итеп суйганымны күрдем»

Ислам галимнәре тәфсирләрдә һәм башка аңлатмаларда шулай диделәр: Ибраһим Пәйгамбәр Исмагыйл улын Корбан итеп суярга теләгәч, улына әйткән булган: «Әйдә, Аллаһы Тәгалә ризасы өчен Корбан чалырга барабыз». Һәм пычак вә җеп алып алар Корбан чала торган җиргә киттеләр.

Әмма юлда аларга өч мәртәбә шәйтан килде һәм Ибраһим Алейһиссәләм шәйтан торган

җиргә 3 тапкыр таш атты.

Вә шуннан башлап Хаҗны үтәгәндә хәҗиләр таш ату гамәлен кылалар, чөнки бу эш Хаҗ гамәлләренең бере.

Ибраһим Пәйгамбәр Исмәгыйл улы белән тау янына җиткәч Исмәгыйл сорады: «Безнең Корбаныбыз кайда?»

Ибраһим Алейһиссәләм шулай җавап бирде: «Әй, улым, мин сине Корбан итеп суйганымны төшемдә күрдем».

Шуны ишеткәч Исмәгыйл әтисенә әйтте: «Мине җеп белән ныгырак бәйлә, мине калтыратмаска тырыш һәм минем каным Сиңа чәчрәмәсен, чөнки әнием күрсә, кайгырар, һәм пычакны минем муеныма тиз ышкып кис, әниемә кайткач, аңа Сәлам әйт».

Ибраһим Алейһиссәләм улын упте, йылады вә әйтте: «Аллаһы Тәгаләнең Әмерен үтәр өчен син миңа бик зур ярәмче булдың», – диде

Аннан соң пычакны алып кисәргә тотынды, әкин пычак кисмәде. Имам Муҗәһид әйтте: Ибраһим Алейһиссәләм бугазларга тотынганда, пычак әйләнеп кисми иде, шунда Исмәгыйл әйтте: «пычакны күтәреп чәнечеп, сугып суй» – диде.

Алар икесе дә Аллаһның Әмерен үтәргә тырыштылар.

Шуннан соң Ибраһим Алейһиссәләмгә ул турында вәхий кильде вә Көръәндә әйтелде:

« وَفَدَيْنَاهُ بِذِبْحٍ عَظِيمٍ »

(Әс-Саффат Сүрәсе, 107 Аят),

Мәгънәсе: Исмәгыйл урынына башка корбанлык бирелде: зур мөгезле сарык тәкәсе.

Бу Кыйсса безгә шуны өйрәтә һәм аңлата: һәр кайсыбызга тәкъвалы булырга тырышырга кирәк, кеше нинди хәлдә булса да: авырлык килсә дә, шатлык булса да, һәр вакыт Бер Аллаһы Тәгаләгә тәвәккәл итәргә тиешбез

Бу кыйсса безнең өчен тагын да бер гыйбрәт, кешенең канәгатен арттыра ки: Пәгамбәрләр – бөек мәхлүкатләр, Көрьәндә Пәйгамбәрләр хаккында бик матур вә мактаулы Аятләр бар, һәм дә әйтелгән: һәрбер Пәйгамбәр бөтен галәмдәге мәхлүкатларның иң яхшысы.

Бәйрәм көннәре дүрт. Шул мөбәрак Корбан Бәйрәме көннәрендә безнең әүвәлге мөселманнарның дөрес булган Ислам гөреф-гадәтләрне белеп, хәерле эшләрне күбрәк кылырга кирәк, мохтаҗларга садака бирергә, туган-ырулар вә якын-йырак карендәшләр белән мөнәсәбәтәребезне яхшырак булсын өчен бер-берсенә кунакка барып хәл-әхвал белешү, арада берәр-нинди авырлык, ачулану булса, кичерүне сорау кирәкле.

Каберстанны Зиярәт итү: зиратларыбызга барып, анда Көрьән вә Догалар укып, хәсыл булган Сәвапларны вафат булган мөселманнарга багышларга бик яхшы вә сәваплы гамәл.

Әмма хәерле эшләрне Бәйрәмнәрдә генә кылу түгел һәр вакыт кылу тиешле.

Бәйрәмнәрдәге вакытны мәнфәгать өчен кулланырга кирәк вә моннан соң башка вакытларда да хәерле эшләр кылырга өйрәнү, гөнаһлардан саклану тиешле

Гыйбадәтләрне дөрес үтәр өчен кирәкле гыйлем алу тиешле. Һәм гыйлемне дә галимнәрдә укыган кешеләрдән алу дөрес була, үз башына китаплардан гына өйрәнгән кешедән гыйлем алу дөрес булмас.

Аллаһы Тәгалә гыйбадәтләребезне кабул итсен, үлгән мөэминнәргә рәхмәт кылсын, чирлеләргә – шифа, барчабызга да һидәять бирсен.

Безнең Хаҗиләргә Аллаһы Тәгалә ярдәм бирсен, Хаҗларын кабул итсен, безнең өчен кылынган Догалар да кабул булып, бездән Пәйгамбәребез Мухәммәд, Аляһиссәләмгә сәламнәр әйтергә нәсып итсен. Хаҗга бармаганнарга да Аллаһы Тәгалә Хәҗ гамәлен кылырга мөәссир итсен.

Газиз мөселман кардәшләр! Корбан Бәйрәме мөбәрәк вә хәерле булсын!